**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге башлыгы карары**

**2022 елның 25 октябре** **№3**

**«Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

*1.* 2022 елның 5 ноябренә 8 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

*2.* 2022 елның 5 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

*3.* 2022 елның 5 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Лельвиж авылында Совет урамы, Яр буе урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Совет урамындагы юлга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт) (вак таш сатып алу, ташу, җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту, территорияне җәй көне чабу; юл кырыен куаклардан һәм агачлардан чистарту; ягулык-майлау материаллары, агрегатлар, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Лельвиж авылында су челтәрен ремонтлау;
- мотопомпа сатып алу;
- Лельвиж авылында су башнясы урнаштыру өчен җир кишәрлеге рәсмиләштерү;
- спорт инвентаре сатып алу;
- Авыл көне бәйрәме үткәрү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Лельвиж авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы Э.Ю. Игнатьева